**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3517**
**16.05.2025**

Ел саен уздырыла торган
«Сабан туе гүзәле - 2025» шәһәр
конкурсы үткәрү турында

Башкарма комитетның 2022 елның 19 октябрендәге 5650 номерлы Карары белән расланган 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын үтәү йөзеннән, шәһәр яшьләре арасында татар милли мәдәниятен, йолаларны һәм гореф-гадәтләрне үстерү, саклау һәм пропагандалау кысаларында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә ел саен уздырыла торган «Сабан туе гүзәле - 2025» шәһәр конкурсын Яр Чаллы шәһәренең «Энергетик» мәдәният сарае» муниципаль автономияле мәдәният учреждениесендә 2025 елның 11 июнендә үткәрергә.

2. Расларга:

1) ел саен уздырыла торган «Сабан туе гүзәле – 2025» шәһәр конкурсын үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) ел саен уздырыла торган «Сабан туе гүзәле – 2025» шәһәр конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә ел саен уздырыла торган «Сабан туе гүзәле – 2025» шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү буенча чыгымнарны финанслауга акча бүлеп бирүне 2025 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәдәният» 0801 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына, 3 нче кушымтада каралганча 72 500 (җитмеш ике мең биш йөз) сум күләмендә тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 16 маендагы
3517 номерлы карарына
1 нче кушымта

Ел саен уздырыла торган
«Сабан туе гүзәле – 2025» шәһәр конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Ел саен уздырыла торган «Сабан туе гүзәле – 2025» шәһәр конкурсы (алга таба – конкурс) Яр Чаллы шәһәре яшьләре арасында татар милли мәдәниятен, йолаларны һәм гореф-гадәтләрне үстерү, саклау һәм пропагандалау максатында үткәрелә.

2.Конкурсның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) яшьләрне милли мәдәнияткә җәлеп итү;

2) талантлы яшьләргә аларның иҗади потенциалларын тормышка ашыруда ярдәм күрсәтү;

3) җәмгыять аңында кызларны гаиләдә дөрес тәрбияләүнең мөһимлеген формалаштыру;

4) татар халкының йолаларын һәм гореф-гадәтләрен саклау.

3. Конкурска әзерлекне һәм аны үткәрүне составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) гамәлгә ашыра.

4. Оештыру комитетының төп функцияләре булып түбәндәгеләр тора:

1) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү эшчәнлеген координацияләү;

2) конкурсны үткәрү турында нигезләмәне, конкурс барышын һәм йомгакларын массакүләм мәгълүмат чаралары аша яктырту;

3) конкурсның жюри составын формалаштыру.

2 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

5. Конкурста 18 яшьтән 25 яшькә кадәр, татар телен белгән, буй озынлыгы 164 сантиметрдан артык булган кызлар катнаша.

6. Конкурс өч турда үткәрелә:

1) сайлап алу туры – «Энергетик» МС» МАМУда (кече зал), (Г.Тукай исемендәге яр буе, 31 йорт);

2) финал (конкурс финалистлары катнашында шоу программа) – 2025 елның 11 июнендә 18:30 сәгатьтә «Энергетик» мәдәният сарае» МАМУда.

7. Сайлап алу турында катнашу өчен әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган форма буенча анкета-заявка һәм гәүдәне тулысынча төшергән фотография җибәрергә кирәк. Катнашу өчен анекета-заявкалар h5r2m80@mail.ru электрон адресы буенча кабул ителәләр.

Россия Федерациясе Граждан кодексының 152.1 статьясы, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, заявка тутырганда һәр катнашучы фотографияләрне һәм видеоматериалны сайтка һәм мәгълүмат стендларына урнаштыруга ризалык бирә.

8. Сайлап алу турына катнашучыларга түбәндәгеләрне әзерләргә кирәк:

1) визит карточкасы (үзе турында прозада, шигъри формада сөйләү, театральләштерү, видеоролик һ. б.) 2 минуттан артык түгел;

2) иҗади номер (вокал, хореография, театральләштерү, нәфис сүз, оригиналь жанр) 3 минуттан артык түгел.

Үзең белән алмаш аяк киеме, сәхнә костюмы, флеш-йөрткечтә фонограмма, фотография булырга тиеш.

9. Сайлап алу туры йомгаклары буенча конкурс жюрие финалистларны билгели.

## 3 бүлек. Конкурска йомгак ясау

10. Чыгышларны бәяләү критерийлары:

1) татар телен белү;

2) сәхнә осталыгы;

3) сәхнә образы (костюм);

4) иҗади индивидуальлек;

5) конкурста катнашучы эшли яки укый торган оешманы күрсәтү осталыгы.

11. Конкурста катнашучылар, бәяләү критерийлары нигезендә, 10 баллы система буенча конкурс жюрие тарафыннан бәяләнә. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә.

12. Иң күп балл җыйган катнашучылар конкурсның җиңүчеләре дип танылалар.

13. Призлы урыннар түбәндәге номинацияләр буенча бирелә:

1) «Иң  шаян» - Самая веселая;

2) «Иң  тапкыр» - Самая находчивая;

3) «Иң  заманча» - Самая современная;

4) «Иң үткен» - Самая шустрая;

5) «Иң иҗади» - Самая талантливая;

6) «Иң мөлаем» - Самая милая;

7) «Иң зифа» - Самая стройная;

8) «Иң ягымлы» - Самая приятная;

9) «Иң зәвыклы» - Самая изящная.

14. Конкурс финалы җиңүчесенә «Сабан туе гүзәле – 2025» титулы бирелә. Сайлап алу туры йомгаклары буенча оештыру комитеты өстәмә номинацияләр билгеләргә хокуклы.

15. Конкурста катнашучылар бүләкләр, чәчәк бәйләмнәре, дипломнар һәм хәситә белән бүләкләнәләр. Төп приз – юллама сатып алуга сертификат.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Ел саен уздырыла торган
«Сабан туе гүзәле – 2025» шәһәр
конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә
кушымта

«Сабан туе гүзәле – 2025» шәһәр конкурсында катнашучы анкетасы

1. Ф.И.А.и.

2. Туган елы (тулы яшь).

3. Туган урыны (шәһәр, өлкә).

4. Адресы, телефоны, E-mail.

5. Паспорт мәгълүматлары.

6. ИНН

7. Эш, уку урыны.

8. Хезмәт стажы.

9. Сезнең хобби.

10. Сезнең сәләтләрегез (кирәклесенең астына сызарга):

а) җырлыйм;

б) музыка уен коралларында уйныйм;

в) бииpermission;

г) шигырь, проза укыйм;

д) башка ______________________________________________

11. Татар телен белү (кирәклесенең астына сызарга):

а) бик яхшы;

б) яхшы;

в) бик үк яхшы түгел;

г) начар.

12. Сезнең буй озынлыгы.